**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 136** **от 15.01.2026 ел**

**Зәй муниципаль районының Сәрмәс-Баш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Сәрмәс-Баш авыл җирлеге Советының 29.11.2013 ел, № 61 карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы

**Карар кылды:**

1. Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советының 29.11.2013 № 61 карары белән расланган Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең 8 пунктындагы 34 абзацы (02.03.2015 ел, no 124, 28.05.2018 ел, no 103 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) 05.11. 2019 ел, № 160, 05.07. 2021 ел, № 31, 07.06.2022 ел, № 60, 23.11. 2023 ел, № 95, 28.12. 2024 ел № 127) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;"».

2. Карарны халык яшәгән урыннардагы махсус мәгълүмат такталарында, Зәй муниципаль районының "Авыл торак пунктлары" бүлеге житәкчесе сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе Г.П.Абрамов